Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№31 (82)

10 октябрь 2013 ел



Влад Михневский фотолары

# Яшьләр өчен махсус нигез!

9 октябрь көнне КФУга Samsung Electronics компаниясе вәкилләре визит ясады. Чарада КФУ ректоры И.Гафуров һәм Samsung компаниясе вәкилләре катнашты. Очрашуда гомуми белем бирү учреждениеләре өчен, IT нигезләр һәм «Samsung Junior IT & Software School» буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру турында сүз барды. Программа биш мең мәктәп укучысын IT технологияләр өлкәсендә булачак белгечләрне укытуга юнәлтелгән. Проект 5 елга исәпләнә һәм ул Россиянең Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Россия хөкүмәте ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Киләчәктә безнең уку йортында да махсус сыйныфлар ачу планлаштырыла.

## • Вакыйгалар әзеннән

Октябрьнең беренче атнасында Кече Филология һәм сәнгать институты үзенең студентлары – республикабыз гомуми белем бирү учреждениеләренең **7-11 СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН ЯҢА УКУ ЕЛЫН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ.** Кече ИФИ директоры Т.Бычкова һәм деканнары Г.Гайнуллина, Т.Пименова, М.Мәхмүтова институтның эшчәнлеге, оештырылган чаралар турында сөйләделәр. Аларның чыгышлары бүлекләрнең төп юнәлешләрен һәм аспектларын чагылдырган видеоязмалар һәм презентацияләр белән үрелеп барды.

• • • •

4 октябрь көнне И.Кант исемендәге Балтыйк федераль университетында «Математика буенча белем бирү һәм хәзерге дөнья» **VII БАЛТЫЙК БЕЛЕМ БИРҮ ФОРУМЫ ҮЗ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ.** Әлеге зур масштаблы чарада 75 югары уку йорты һәм фәнни учреждениеләрне тәкъдир итүдә 23 илдән 500дән артык тикшерүче-галимнәр катнашты. Форум кысаларында Россиянең барлык федераль университетлар ректорлары катнашында уздырыла торган «Клуб девяти» утырышы да булды. Утырышта Казан университетыннан уку-укыту эшләре буенча проректор Р.Минзарипов катнашты.

• • • •

5 октябрь көнне университетыбызда **КҮЗӘТҮЧӘНЛЕК СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Очрашуда КФУның Юл картасы, КФУ Уставына кертелергә мөмкин булган үзгәрешләр һәм университетның алга таба үсешенә бәйле мәсьәләләр каралды. РФнең Мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Н.Третьяк Казан федераль университетының Күзәтүчәнлек советы рәисе итеп сайланды.

• • • •

Яр Чаллы филиалы студентлары **А.АНДРЕЯНОВ** һәм **Р.ГОРДЕЕВ** VIII Россиякүләм форумда катнаштылар. Алар Россиякүләм гомуми белем бирү һәм фәнни учреждениеләр арасында үткәрелә торган яшьләр конкурсында «Моя законотворческая инициатива» темасы белән чыгыш ясадылар. Егетләр **II УРЫНГА ЛАЕК ДИП ТАБЫЛДЫЛАР** һәм, шул рәвешле, форумның призерлары исемлегенә керделәр.

• • • •

Казан университеты профессоры, Филология һәм сәнгать институтының рус телен чит тел буларак укыту кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы **Т.БОЧИНА** 2012-2013 уку елында NSLI-Y телләр буенча академик программаны гамәлгә ашыруга керткән зур өлеше өчен **РӘХМӘТ СЕРТИФИКАТЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ**. Мондый сертификат АКШ Дәүләт департаментының Белем бирү һәм мәдәният бюросының югары бәясе булып тора һәм ул АКШ һәм Россия арасында үзара аңлашуны ныгытырга ярдәм итә.

• • • •

2013 елның октябрь башында КФУның Өзлексез белем бирү институтында **«СОЦИАЛЬ ӨЛКӘДӘ ИДАРӘ ИТҮ» ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАСЫ БУЕНЧА УКУЛАР** (квалификация күтәрү) **ТӘМАМЛАНДЫ**. 15 көн эчендә Россиянең дүрт төбәгеннән – Пермь өлкәсе, Удмуртия, Марий Эл һәм Татарстан – мәктәп директорлары һәм дәвалау учреждениеләренең баш табиблары университетта белем эстәделәр. Курсларның тәмамлануы тантаналы рухта узды.

• • • •

7 октябрьдә Геомагнетизм буенча **ФӘННИ СОВЕТ** үзенең традицион геомагнитизм, палеомагнетизм һәм магнетиз мәсьәләләре: теория, практика, эксперимент буенча **ХАЛЫКАРА СЕМИНАР ҮТКӘРӘ**. Чара Россиянең фундаменталь тикшеренүләр фонды, Казан федераль университеты, Россия фәннәр академиясе президиумы һәм Норвегиянең мәгариф өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек үзәкләренең матди ярдәме белән оештырыла. Ул 12 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

• Чара

# АКШ Россия тәҗрибәсен куллана

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

9 октябрь көнне Н.И.Лобачевский ис. фәнни китапханәдә «Россия һәм АКШта педагогоик белем бирү системасының яңартылуы: проблемалар һәм аларны чишү юллары» исемле Халыкара Россия-Америка семинары булды. Чараны КФУның Педагогика һәм психология институты оештырды.

«Казан университетының Педагогика һәм психология институты быелгы көздә берничә халыкара семинар уздырырга ниятли. Бүген менә – математика белеме буенча Россия-Америка семинары, ноябрьдә – Төркиядәге коллегаларыбыз белән башлангыч белем бирү мәсьәләләре, ноябрь ахырында формаль булмаган белем бирү буенча Россия-Германия семинары булачак. Әлеге чаралар төрле илләрдә булган тәҗрибәләр белән уртаклашырга һәм Казан университетындагы педагогик белем бирүне модернизацияләргә ярдәм итәчәк», – дип белдерде институт директоры **Айдар Калимуллин**.

Россия-Америка семинарының төп максаты булып, педагогик белем бирү системасын реформалаштыру тәҗрибәсе белән уртаклашу, Казан федераль университетының Эль Пасодагы Техас университеты (Техас, АКШ) белән хезмәттәшлек юлларын билгеләү тора.

Америка тәҗрибәсе белән уртаклашу өчен, педагогика фәннәре докторы, югары математика һәм укытучылар әзерләү кафедралары профессоры, «Милли куркынычсызлык буларак математик белем бирү» докторлык программасы җитәкчесе **Мурат Чошанов** (*өстәге фотода*) килгән иде. Аның фикеренчә, математика ул – Россиянең иң көчле бренды һәм башка илләргә аннан өйрәнер әйберләр байтак: «Бу семинар Кушма Штатларда әлеге өлкәгә бәйле ясалган хаталарга багышланган. Мин күңелемдә үземне Россияле дип саныйм һәм шул ялгышларны Россиядә кабатламауларын теләр идем. Америкалылар үзләренең һәм башкаларның хаталарыннан өйрәнә, ничек кенә парадоксаль яңгырамасын, бүгенге көндә АКШ Россия тәҗрибәсен куллана башлады». Техас галиме концепцияләр булдыручыларга Американың тискәре тәҗрибәсенә күз салырга киңәш итте. Төрле тест, БДИларны укыту системасына керткәндә, бик игътибарлы булырга кирәк, чөнки хәзер Америкалылар тест системасыннан баш тарталар һәм безнең укыту системасы белән кызыксыналар икән. М.Чошанов үзенең чыгышын математика буенча белем бирүдәге системалы хаталарга багышлады. Аеруча тестлар белән бик сак булырга, фәннең фундаментальлеген сакларга өндәде.

Алга таба университетыбыз галимнәре дә математик белем бирү мәсьәләләренә тукталдылар. Гомумән алганда, семинарда берничә юнәлеш яктыртылды: математика буенча белем бирүнең төп проблемалары, АКШ һәм Россиядә педагогик белем бирү проблемаларының төп юнәлешләре, укытучыларны профессиональ яктан үстерү өчен ярдәм пространство булдыру, хәзерге педагогик белем бирүнең методологик һәм методик проблемалары h.б.





*Влад Михневский фотолары*

• Сәләткә сәбәп кирәк

8 октябрь көнне Филология һәм сәнгать институтында студентлар һәм аспирантлар өчен «Хәзерге драматургия һәм театр проблемалары» исемле Халыкара фәнни мәктәп үз эшчәнлеген башлап җибәрде.

# Германиялеләр – татар сәхнәсендә!

**Диана АГАПОВА,**
Матбугат үзәге

Казан университеты һәм Юстус Либиг исемендәге Гиссенс университеты (Германия) студентлары һәм укытучылары хәзерге драматургия һәм театр проблемалары турында сөйләшергә һәм фикер алышырга җыелдылар. Казан университетының чит ил әдәбияты кафедрасы доценты, Халыкара фәнни мәктәпнең оештыру комитеты әгъзасы **Елена Шевченко** сүзләренчә, әлеге проект 2007 елда университет хезмәткәрләре инициативасы белән барлыкка килә. «Без Гиссен университетындагы коллегаларыбызны хезмәттәшлек итәргә чакырдык. Проектның максаты – хәзерге чор драматургиясе мәсьәләләрен өйрәнү һәм аларны хәл итәргә тырышу. Бүгенге көндә без драматургиядә радикаль үзгәрешләр күзәтәбез. Мәдәният үзгәргән сыман, театрның теле дә үзгәреш кичерә. Мондый очрашуларда без студентлар һәм коллегалар белән театрның бүгенге халәте, хәзерге драматургларны борчыган мәсьәләләр, драматургиянең формасы үзгәрүе турында фикер алышабыз», – диде.

Гиссенс университетының Славистика институты профессоры **Александр Граф**, мондый тәкъдимне ишеткәч, аны кире кага алмавы турында әйтте: «Безнең университет КФУ белән инде күптәннән хезмәттәшлек итә һәм безнең уртак проектлар саны да байтак. Мондый мәктәпне булдыру идеясе безгә бик кызык булып тоелды. Хәзерге драматургия һәм театр проблемаларын һичшиксез өйрәнергә кирәк!»

Халыкара фәнни мәктәп чиратлашып Гиссен һәм Казанда үткәрелә. Проект кысаларында, КФУ Германиядәге дусларын инде дүртенче тапкыр кабул итә. Быел Профессор Граф үзе белән 12 студентын да алып килгән. Проектның программасы бик тыгыз: катнашучыларны кызыклы лекцияләр, интерактив дәресләр, доклад яклаулар, спектакль куелышлары, танылган драматург һәм сценаристларның мастер-класслары көтә. Фәнни мәктәп эшендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының ярдәме зур. Бу театрда студентлар режиссер Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелегендә Й.Фоссеның «Бервакыт җәйге көндә» пьесасын куячаклар.

Шунысын да әйтергә кирәк: мәктәп чаралары рус телендә үтә. Германиядән килгән студентларның барысы да рус телендә бик әйбәт сөйләшә, алар проект кысаларында «Өч сеңел», «Ревизор» әсәрләрен сәхнәләштереп күрсәтәчәк. Гиссен университеты вәкиле булган **Наталия Пфайфер** шулай ук бу спектакльләрдә катнашачак. «Минем әтием – немец, ә әнием – рус. Без Германиягә миңа сигез яшь булганда күчеп киттек. Проектка килгәндә, бу бик кызык һәм файдалы дип уйлыйм. Университетыгыз да бик ошады».

Фәнни мәктәпнең эшчәнлеге 12 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Бүген программада хәзерге драматургия һәм театр өлкәсендәге белгечләр белән очрашу каралган. Анда Казан, Мәскәү, Самара, Түбән Новгород һәм Лодзь (Польша) шәһәрләреннән фәнни хезмәткәрләр катнашачак.



• Без кунакта

# Экран арты серләре

**Раил САДРЕТДИНОВ,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Телевидение дигән дөнья үзендә нинди серләр саклый? Без телевизордан караган тапшырулар ничек туа? Аларны кем әзерли? Бу һәм башка бик күп сорауларга җавапны татар журналистикасы бүлегенең II курс студентлары «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе хозурына үткәрелгән экскурсиядән белеп кайтты.



Телевидениегә бару теләге бездә шулкадәрле көчле булган ки, хәтта билгеләнгән вакыттан алда килеп җиттек. Безне биредә укытучыбыз **Мөршидә** апа **Фатыйхова** каршы алды. Телевидение территориясенә үтеп керү җиңел түгел. Шулай булырга тиеш тә, телевидение ул «дүртенче хакимият» ролен башкара.

Бина эченә керүгә, безне үз артыннан ияртеп, «Манзара» тапшыруын алып баручы **Миләүшә** апа **Сибгатуллина** алып китте. Телевидение коридорлары буйлап атлыйбыз... Диварда уңыш күрсәткечләре: төрле елларда, төрле бәйгеләрдә җиңеп алган диплом-грамоталар. Болар бит барысы да – тырыш хезмәт, журналистларның үз эшләренә яратып, җаваплы карау нәтиҗәсе.

Иң беренче булып студиягә кердек. Барлык тапшырулар диярлек биредә төшерелә икән. Без «Манзара» тапшыруын төшергән вакытка туры килдек. Монда без, тапшыру тамашачыга барып җитсен өчен, алып баручының гына түгел, ә башкаларның да: операторлар, ут куючыларның хезмәте бик мөһим икәнлегенә төшендек. Студиянең заманча технологияләр белән җиһазландырылганлыгы сөендерде. Ләкин 24 сәгать буе безне Ватаныбыз вәзгыяте белән таныштырып, рухи яктан баетып тора торган телевидение карамагында бер генә студия булу бик кызганыч, әлбәттә.

Алып баручы, оператор, режиссерларның эше тәмам. Ләкин андый форматта тапшыруны эфирга чыгарсаң, тамашачыларның аңлап бетермәүләре бар. Зәңгәр экраннар аша безгә килеп ирешкәнче, тапшыру бик зур юл үтә. Моның өчен мөхәррир, монтаж ясаучы аеруча тырыша.

Бүген рекламасыз нәрсәгенә эшләп була икән? «Яңа Гасыр» каналы да искәрмә түгел. Реклама бүлеге хезмәткәрләрен психологлар белән чагыштырдым. Алар уйлап чыгарган «продукт» бик кызыклы да булырга, шул ук вакытта кешене ялыктырмаска да тиеш. Рекламаның тәэсирен көчәйтү өчен, күпме хезмәт куелганын аңлау авыр түгел.

Һәркайсыбызның да зур кызыксыну һәм игътибар белән карый торган тапшыруы – «Хәбәрләр»дер, мөгаен. Редакция журналистлары эшләрен җиренә җиткереп башкара, алар безне иң соңгы яңалыклар белән нәкъ вакытында туган телебездә таныштырып бара.

ТНВда бара торган чит ил сериалларының татарча тәрҗемәсе кайда эшләнгәнлеге турында ишетеп кенә белә идем. Чит ил актерлары «Дубль видео» студиясендә татарча «сөйләшә» икән. Бу студия телевидениенең башка редакцияләреннән тынлыгы, ниндидер сихрилеге белән аерылып тора. Әйтерсең, син башка дөньяга килеп эләгәсең.

Телевидение – үзе үк серле дөнья. Биредә көн дә, төн дә юк. Монда эшләүчеләр өчен, башкарган эшнең нәтиҗәсе, халыкка тиешле вакытта һәм дөрес итеп барып ирешүе, тамашачылар мәхәббәте мөһим.

Бу экскурсиядән без «Американы ачкандай» кайттык. Күпме сорауларга җаваплар табылды, киңәшләр ишеттек, телевидениедә эшләүнең үтә җаваплы эш икәнен аңладык. Нәкъ шуңа күрә һәрберебезнең күңелендә «Эх, мин дә биредә эшләр идем», – дигән теләк тумый калмагандыр.

• Тарих сәхифәләреннән

# Хәтер барлау кирәкме?

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

15 октябрь – Татарстанда Хәтер көне. Иске стиль белән ул 12 сенә туры килә. Хәтер көне – милләтебез тарихында гаять зур һәм фаҗигале дата. Әмма без аны дөрес үткәрәбезме? Хәтер көненең асылын дөрес аңлыйбызмы?



Татар тарихы... Мондый бәхәсле, фаҗигале тарих сирәк бу дөньяда. «Халыкның милли үзаңын бары тик бер юл белән генә күтәрергә буладыр. Ул да булса, аның тарихындагы барлык вакыйгаларны, дәверләрне ачыклау, халкыңның меcкенлеген түгел, батырлыгын, кыюлыгын күрсәтү. Әгәр дә татарның милли үзаңы милләтенең тарихы биеклегенә күтәрелә алса, татар нинди шартларда да телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен югалтмас иде», – дип язды тарихчы Илдус Хуҗин.

Татар тарихына караган кайбер мәгълүматлардан хәбәрдар булсак та, аны тулысынча беләбез, дип әйтү шикле тоелыр иде. Хәтер көнен генә алыйк. Ни кызганыч, мәктәптә укучылар, хәтта студентларның билгеле бер өлеше дә, Хәтер көне турында бөтенләй мәгълүматсыз.

Моннан 461 ел элек татар, ногай, удмурт, мордва, чуаш һәм марилардан торган 30 мең кешелек гаскәр русларның 180 меңлек армиясенә 41 көн буе каршы тора, ләкин җиңелә. Казанны Иван IV гаскәрләреннән яклап шәһит киткән бабаларыбызны искә алу көне ул – Хәтер көне. 1989 елның 15 октябреннән билгеләнеп үтелә башлаган бу датаны әлегәчә Казанның үзәк мәйданына җыелып хәтердә яңарта халык. Әмма елданел Хәтер көненә җыелучы кешеләр саны кими бара. Җыелганнарының күпчелеге–өлкән яшьтәгеләр. Яшь буын юк дәрәҗәсендә. Мина калса, соңгы елларда Хәтер көне ниндидер бер тамашага кайтып кала төсле. Безнең кемнедер вәхшилектә гаепләп, нәфрәтләнеп, урам буенча кычкырып йө-рүебез, сәясәт белән артык мавыгып китүебез әлеге көннең асылын бөтенләй юып ташлый. Бу, әлбәттә, Хәтер көнен билгеләп үтү кирәкми, дигән сүз түгел. Кирәк, ничек кенә әле! Киләчәк буынның иминлеге, милләтебезнең сакланып калуы өчен башларын салган бабаларыбызны онысту иң зур мәнсезлек булачак. Хәтерләргә кирәк! Әмма башкачарак, минемчә. Бу көнне һәлак булганнар рухына атап дога кылу, хәер бирү савыплы эш саналыр иде.

Икенче яктан, бу көн – тарихтан гыйбрәт алу көне дә. Татар халкы үзара бердәм булмау сәбәпле, кайчандыр гөрләп торган Казан, Себер, Әстерхан, Нугай ханлыкларыҗимерелгән. Үзара низаглар, хакимиятне бүлешә алмау, ызгыш-талаш аларны тарих мәйданыннан төшереп калдырды. Хәтер көнендә без болар хакында да онытырга тиеш түгел. Бу көнне кемнедер каргап, кемгәдер нәфрәтләнеп түгел, ә дәүләтчелегебезне югалтуның төп сәбәпләре турында уйланып үткәрү күпкә файдалырак булыр иде. Юкса, һаман да бер-беребезгә каршы булып, юк өчен дә ызгышып яшәвебезне дәвам итәбез, тарихтан сабак ала белмибез.

Бүген урамга чыгып, «Азатлык, бәйсезлек кирәк!» – дип кычкырып йөрү белән берәүне дә шаккатырып булмый. Чөнки вакыты ул түгел: 90 елларда бу актуаль булды, чөнки сәяси хәл башка иде. Минемчә, иң мөһиме – Хәтер көне 1552 елгы фаҗигане хәтерләвебезне күрсәтергә тиеш. Моның өчен эшне балалар бакчасыннан ук башларга кирәк. Нинди көн ул? Аның төп асылы нидә? Кем кем белән һәм нәрсә хакына көрәшкән? Боларның һәммәсен балаларга бәйнәбәйнә аңлатырга кирәк. Кечкенәдән үк тарихын белгән буын гына әлеге көннең хәзерге форматын үзгәртеп, аны чынчынлап Хәтер көненә әйләндерә алачак.

*Шау-шулы*
*вакыйгалар да,*
*аны тудырган зур*
*шәхесләр дә ерагая.*
*Яңа вакыйгалар*
*туа торганга,*
*әкренләп суына*
*баралар - хәзерге*
*хәлләр бәгырьгә*
*тия, тегеләре өчен*
*бүтәннәр сызланган,*
*ул хатирәләр аларга*
*гына кадерле.*
Ш.Галиев.


Республикабызда төрле милләт һәм конфессия вәкилләре гомер кичерә. Аларның һәркайсы күпмилләтле Татарстанның кабатланмас бизәге булып тора һәм аның үсешенә гаять зур өлеш кертә. Нәкъ менә шушы үзенчәлек Татарстанның милли-мәдәни байлыгын хасил итә дә инде.

# Лаеклы өлеш кертик!

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Иң мөһиме – республикада барлык халыклар да дустанә мөнәсәбәтләрдә, берберсенә карата якын туганнар кебек, тату гомер кичерә. Аларның һәркайсының рухи-мәдәни үсеше өчен уңай шартлар тудырылган. Күп телләрдә газета-журналлар, китаплар нәшер ителә, мәктәпләрдә һәр баланың диярлек үз туган телендә уку мөмкинлеге бар, әледән-әле төрле иҗади конкурслар, фестивальләр, мәртәбәле бәйгеләр булып тора, тарихи-мәдәни үзәкләр гаять зур эш алып бара. Саный китсәң, бу хакта бик озак сөйләргә мөмкин.

Аңлашыла: әлеге чаралар төбәктә гомер кичерүче халыклар арасында милли-мәдәни бәйләнешләрнең дә, эшлекле диалогның да, дуслык җепләренең дә ныгуына хезмәт итә. Шул ук вакытта, без, яшь буын да, әлеге эшкә лаеклы өлешебезне кертергә тиеш. Шәхсән мин моны, беренче чиратта, туган телне, әдәбиятны, мәдәниятебезне яратуда һәм хөрмәт итүдә, иҗтимагый процессларда, җәмгыять тормышында актив катнашуда, республикабыз җитәкчелеге үткәргән барлык мөһим башлангычларны күтәреп алырлык һәм лаеклы дәвам итәрлек көчле буын булып үсеп җитүдә күрәм. Һәм яшьтәшләремне дә шушы максатка тугры булырга чакырам. Татарстаныбызның киләчәктә дә чәчәк атуын, милләтләр дуслыгы бишеге булуын телибез икән, һәрберебез яшь чактан ук бу турыда җитди уйланырга тиеш.



• Авыл хәлләре

Шушы көннәрдә Универсиада Авылында яшәүчеләрнең традициягә әйләнгән, сәламәтлек көненә багышланган спартакиадасы үтте.

# Салкын безне куркытмый!

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Бу чарага җыелган студентларның һәрберсе – интеллектуаль, иҗат, спорт ягыннан актив кешеләр. Чөнки чара спортны гына аерып алмый, анда үзеңне төрле яктан күрсәтергә кирәк. Әйтик: турникта күтәрел, капчык киеп йөгер, велосипедта кискен борылышларны үт; үзеңне иҗатта күрсәт: бие, җырла, шаяр; интеллектуаль яктан иң зирәге итеп таныт – җаның ни тели, катнаш кына! Ярышларда чит илдән килеп белем алучы студентлар да актив катнаша икән.

«Күркәм традициягә әверелергә өлгергән бу чараны Универсиада Авылында һәр елны уздырабыз. Ярыш Универсиада Авылы йортлары арасында үткәрелә. Һәр йорт командасында өч кыз һәм өч егет катнаша. Ярыш җиде этаптан тора. Команданың уңышлары маршрут картасында билгеләп барыла. Быелгы ярышларда катнашу өчен, егермедән артык команда теркәлү узды», – дип билгеләп үтте Идарә һәм территориаль үсеш институтының 5 курс студенты, чараны оештыручыларның берсе **Илнур Садыйков**.

Универсиада авылы территориясе – сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен менә дигән территория. Ярыш үткән көннең дә салкын булуына карамастан, катнашучыларның йөзендә елмаю, шатлык балкып тора. КФУның спорт эшләрен оештыру рәисе **Марат Вакказов** та, үз фикерләре белән уртаклашып: «Универсиада авылында спорт сезонының ачылуына бик тә шатмын. Без бер ярыш белән генә чикләнергә уйламыйбыз. Әле алда бик күп уеннар булачак», – диде.

Сәламәт яшәү рәвешенә багышланган чара бик күңелле үтте. Командалар үзләрен бар яктан да танытырга тырышты. Нәтиҗәдә җиңүчеләр дә билгеле булды. Урын алмаган командаларга да борчылырга кирәкми. Спорт белән шөгыльләнү – ул үзеңне җиңү дигән сүз. Ә мондый чараларда җиңүдән дә бигрәк катнашу мөһим.

• Олимпиаданы каршылап

# Волонтерлар әзер!

**Юлия ГАЯЗОВА,**
Яр Чаллы институты

Шушы көннәрдә Яр Чаллы филиалы студентлары волонтерлар әзерли торган укуларның икенче этабында катнашты.

Вакытның ничек тиз узганын сизми дә калабыз. 2014 елда Сочида узачак Кышкы Олимпия һәм Паралимпия уеннары башланырга да нибары дүрт ай калып бара. Зур темплар белән дөньякүләм чарага әзерләнәләр: спорт объектларын төзиләр, спортчылар төрле ярыш мәйданнарын сынап карыйлар, ә волонтерлар белем һәм күнекмәләрен арттыруны дәвам итә. Пенза, Самара, Магнитогорск, Мәскәү, Түбән Кама, Чаллы һәм башка шәһәрләрдән килгән студентлар укуларның икенче этабында үзләре башкарачак эшләр белән тагын да якыннан таныштылар.

Волонтерларның бөтен сорауларына Казандагы «Волонтерларны җәлеп итү» үзәге директоры **Р.Вәлиуллина** җавап бирде. Студентларны шулай ук уеннар ачылу һәм ябылу тантанасы тарихы, төп атрибутлар белән таныштырдылар. 7 һәм 23 февральдә булачак шоу зур сер булып саклана, ләкин оештыручылар аның онытылмас һәм кабатланмас булуын яшерми. Укулар бик күңелле ноктада төгәлләнде. Һәр волонтер кәгазьгә үз хыялын язып, теләкләр агачына элде.

Волонтерлар кайсы шәһәрдән, нинди яшьтә булуга карамастан, аларны бер максат – Олимпия һәм Паралимпия уеннарын тарихка кереп калырлык итеп уздыру берләштерә.

● Туган көн

# Безгә ИКЕ яшь!




**Динара МИННЕКАЕВА,** мөхәррир

2011 елның 6 октябрендә Казан федераль университетында чыга башлаган «Дарелфөнүн» газетасына 2 яшь тулды!

ИКЕ яшь! Без инде аякта нык басып торабыз! Мактанырлык уңышларыбыз, башкалар белән уртаклашырлык тәҗрибәбез, ике ел эчендә эшләгән эшебезнең нәтиҗәсе бар. Без бүгенге көнгә 82 номер чыгардык, шуларның дүртесе – махсус чыгарылыш: абитуриентлар һәм беренче курслар өчен әзерләнгән газеталар.

Камиллеккә, һәрвакыт үсешкә, яңалыкка омтыла торган җирдә үзгәрешләр булу – табигый күренеш. Газетабызның «әти»се булган Рамил Ханнанов салган традицияләрне саклап, без яңа составта газетага күп кенә яңалыклар кертергә дә тырышабыз. Яңа сәхифәләр, яңа танышлар укучыларыбызның көннән-көн артуы турында сөйли. Ә бу чынлап та шулай. Редакциягә һәрдаим кереп, безнең хәл-әхвәлләрне сорашып йөрүчеләр арасында студентлардан башлап, хөрмәтле профессорларга кадәр бар. Алар безне киңәш-тәкъдимнәре, кызыклы язмалары белән сөендереп, канатландырып тора. Бу уңайдан Филология һәм сәнгать институты, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты җитәкчелегенә, укытучыларына, студентларына аеруча рәхмәт әйтәсем килә. Биредә укучылар «Дарелфөнүн»нең иҗат итә башлаучылар өчен менә дигән мәйдан икәнен аңлый. Соңгы саннарда газетаның тагын да камилләшүен сизгәнсездер. Барыбызның да яраткан, хөрмәтле укытучысы Рауза Әмин кызы Асылгәрәева – хәзер безнең хезмәттәшебез. Рауза апа газета битләрендә калган хаталарны төзәтеп кенә калмый, ә онытылган кагыйдәләрне искә төшерергә дә ярдәм итә. Редакция телефонына килгән шалтыратулар башкалабыз мәктәпләрендә генә түгел, ә республикабызның башка авыл-шәһәрләрендә дә укучыларыбыз барлыгы турында сөйли. Алар да уку йорты эшчәнлеге, аның мәртәбәле шәхесләре, студентлар иҗаты белән таныштырып торуыбыз өчен рәхмәтле. Электрон адресыбызга килгән хатлар Казаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең дә татар студентлар газетасына битараф булмауларын күрсәтә.

Газета әзерләүчеләр өчен нәрсә мөһим икән, диярсез. Кызык сорау... Журналист халкы (радиода, телевидениедә, газета-журналда яисә Интернетта эшлиме) үзен мактаганны, кайбер чакта тәнкыйть иткәнне ярата. Ләкин иң әһәмиятлесе, безгә һәрвакыт игътибар кирәк. Боларны үз укучыларыңнан ишетү икеләтә бәхет! Ә инде синең эшчәнлекне тагын да югары бәялиләр икән, сайлаган һөнәреңне ныграк ярата башлыйсың. Ике ел эчендә безнең газета да зур мактауларга лаек булды. Республика күләмендә без «Ел студенты – 2012» студентлар премиясе кысаларында «Студентларның иң яхшы массакүләм матбугат чарасы» исеменә лаек булдык. IV Бөтенроссия балалар һәм яшьләр массакүләм матбугат чаралары «МедиаПокорение» фестивалендә «Иң яхшы корпоратив басма» номинациясендә беренче урынны алдык. Җиңүләребез моның белән генә чикләнмәс әле. Редакция хезмәткәрләре дә төрле иҗади бәйгеләрдә җиңү яулап тора. Аларда да безне «Дарелфөнүн»челәр буларак беләләр.

Гадәттә, нindидер эшчәнлекне яңа туган бала белән чагыштырып күрсәтергә яраталар. Ике яшьлек баланың һөнәрләре күзгә күренеп арта. Безнең ике яшьлек газетаның да үз стиле, сәхифәләре, хәбәрчеләре, укучылары һәм кабатланмас йөзе бар. Бөтен дөньяны шаулаткан XVII Җәйге Универсиада ярышларыннан да читтә калмадык. Спорт чараларын, анда катнашучы спортчылар тормышын үзебез күргәнчә яктыртырга тырыштык. Редакция хезмәткәрләре сезнең, хөрмәтле укучыларыбызның, теләк-тәкъдимнәрен истә тотып эшли. Идел буе округында гына түгел, ә Россиядә, хәтта бөтен дөньяда билгеле Казан университетыбыз базасында татар газетасы чыгу татар студентларының ни дәрәҗәдә актив, максатчан, матбугатыбызны саклап калу өчен тырышулары турында сөйли.

Хөрмәтле укучыларыбыз, иҗатташ дусларыбыз, Бәйрәм көнендә сезгә мөрәҗәгать итеп, безнең белән бергә булуыгыз өчен рәхмәт сүзләре җиткерәсем килә. Бергә булыйк, иҗат утында янып яшик!

**Гөлнур АЙЗАТУЛЛОВА,**
шагыйрә

* * *

*Дарелфөнүн,*
*дарелфөнүн!*
*Сине сагынып уза көнем!*
*Әдәбият дөньясына*
*Алып чыккан затлы*
*телем!*

*И кадерле,газиз телем,*
*Бирдең илһам, бирдең*
*белем.*
*Берни таләп итми генә,*
*Яшисең син җанда*
*минем!*



**ЛӘЙСӘН ИСХАКОВА,**
**Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студенты, хәбәрче:**

«Чыга башлаган көненнән бирле, «Дарелфөнүн» газетасын тәнәфесләрдә төркемдәшләрем белән бергәләп укый идек. Быелдан исә мин университетта булган барлык вакыйгаларны яктырткан бу газетаны читтән генә түгел, ә эчтән торып күзәтә башладым, чөнки мине «Дарелфөнүн»гә эшкә алдылар! Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында уку дәверендә берничә редакциядә практика узарга туры килде. Әмма чынлап торып эшләү мөмкинлеге турында белгәч, бик сөендем, әлбәттә! Чөнки журналист кеше үзенең каләмен һәрдаим шомартып торырга тиеш. Әле дә хәтеремдә: социаль челтәрләрнең берсендә «Дарелфөнүн»гә корреспондент кирәк» дигән хәбәрне күреп алып, күрсәтелгән номерга шалтыраттым. Мине редакциягә чакырдылар. Бардым. Динара Миннекаева белән Алинә Садыйкова беренче көннән үк кочак җәеп каршы алдылар. Рәхмәт аларга! Дус, бердәм булып эшлибез, Аллага шөкер! Миңа редакциядәге иҗади атмосфера, үзара дустанә мөнәсәбәт ошый. Тәҗрибә туплау өчен менә дигән иҗат мәйданы да миңа «Дарелфөнүн».

Яраткан газетабызны туган көне белән котлап, озын якты юл телим. Киләчәктә дә шундый югары иҗади үрләргә менеп, җиңүләр яулап, уртак сөенечләр белән яшәргә язсын иде!»



**РАУЗА АСЫЛГӘРӘЕВА:**

«Дарелфөнүн… Бик кадерле сүз. Газета исеме икәне билгеле булгач, баштагы мәлдә русча газетаның тәрҗемә варианты түгелме, дигән шик туды. Ләкин ул аз гына ваыкт эчендә үзен мөстәкыйль эчтәлекле, стильле, фикерле газета итеп таныта алды. Газетаның редакторы, хәбәрчеләре үзебез тәрбияләп чыгарган студентлар булу да йөрәкләргә сары май булып ята: студентларыбыз бер дигән укытучы икәнлекләрен күрсәтү белән бергә, сәләтле журналистлар, күзәтүчән, мантыйклы, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтенә тирәнтен кереп эшли белүче шәхесләр икәнлекләрен дә бик акыллы итеп дәлилләп киләләр.

Газета укучыларыбыз университет җитәкчелегенә һәр ике дәүләт телендә газета чыгару мөмкинлеген тәэмин итүе өчен дә бик рәхмәтле. Газета, беренче чиратта, татар журналистикасы бүлеге студентларына һөнәри тәҗрибә туплау өчен игелекле мәйдан. Башка институт һәм факультетларның татар телендә әдәби иҗатка кереп китәргә теләге булган студентлар да газета битләрендә каләмнәрен чарлыйлар. Афәрин, «Дарелфөнүн»! Ак юллар, зур уңышлар сиңа!»



**ИЛМИР ВӘЛИЕВ,**
**Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты студенты, хәбәрче:**

«КФУда укый башлау белән, мин математика һәм механика дөньясы белән беррәттән, илһам һәм иҗатка да кереп «чумдым». Монда укый башлаганчы, мин «Дарелфөнүн»нең беренче мөхәррире Рамил Ханнанов белән таныш идем. КФУда укуымны белгәч, ул миңа әлеге газета турында әйтте. Шуннан башлап, мин бу газетада институтыбыз тормышын яктырта башладым. Газетага язу белән генә чикләнмичә, Филология һәм сәнгать институты базасында эшли торган «Илһам» әдәби-иҗат түгәрәгенә дә йөрим. «Дарелфөнүн»дә эшли башлавым өчен, газетаның хәзерге мөхәррире Динара Миннекаевага рәхмәтлемен. Ул тәкъдим итмәгән булса, журналистика белән мавыгуым бөтенләй дә сүрелгән булыр иде. Шундый бердәм, ярдәмчел редакциягә эшкә урнашуыма, коллективтагы кешеләр белән танышуыма мин чиксез шат. Редакциягә керсәң, көне буена җитәрлек позитив һәм күтәренке кәеф алып чыгасың. Студент булуыма карамастан, бу эш миңа аралашу, тәҗрибә туплау, яңа дуслар табу, иҗат итү, вакытны дөрес бүләргә өйрәнү мөмкинлеген дә бирә. Шуны да әйтергә кирәк: журналистика серләренә өйрәтүче Яңа Чишмә районы Зирекле авылы лицееның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәния Зариповага да рәхмәт. Аның җитәкчелегендә без мәктәп газетасын чыгара идек. Нәкъ менә шунда туплаган тәҗрибә журналистикага кереп китүемә этәргеч булгандыр да. Яраткан газетабызны һәм коллективымны ике яшьлек туган көне белән чын күңелдән котлыйм. Алга таба да бергә дус гаилә булып яшәргә насыйп итсен!»

## Безне котлыйлар!

«Газета укырга яратмасам да, «Дарелфөнүн»нең һәр санын карап барырга тырышам. Редакция коллективына безне уку йортындагы иң соңгы яңалыклар, студентлар тормышы белән таныштырып торулары, кызыклы язмалары, файдалы киңәшләре өчен зур рәхмәт. Алдагы көннәрдә газета тагын да камилләшсен, үссен, тиражы да артсын. Татар студентлар газетасының гомере бик озын булсын!»

***Равилә Әхмәтова,***
*Идарә һәм территориаль үсеш институты студенты.*

«Дарелфөнүн» газетасы яшь газеталардан саналса да, аның үз дәрәҗәсе бар. Газетам, сине туган көнең белән чын күңелемнән тәбрик итәм. Киләчәктә дә тырыш хезмәткәрләрең ярдәмендә үс, зур дәрәҗәләргә иреш! Безне һәрдаим кызыклы мәгълүматларың, сәхифәләрең белән сөендер. Сине яратып һәм атна саен көтеп алган укучың»,

***Нурсөя Минзина***, *Филология һәм сәнгать институты.*

«Мин «Дарелфөнүн»не чын күңелемнән туган көне белән котлыйм һәм аңа киң мәйдан, күп укучылар телим. Газетада студентлар үзләрен борчыган мәсьәләләр, шатлыклары белән уртаклашалар, фикер алышалар. Шунысы гына бераз кызганыч: ул мин бишенче курста укыганда гына үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Эх, әгәр иртәрәк чыга башлаган булса, ул безнең студент елларын тагын да кызыклырак, ямьлерәк иткән булыр иде!»

***Әлфия Садыйкова,*** *КФУның 2012 ел чыгарылыш студенты.*

«Башкалабыздан ерак торсам да, «Дарелфөнүн»нең электрон версиясе аша һәр сан белән танышып барырга тырышам! Бик эчтәлекле, файдалы, күп мәгълүматлы газета. Алга таба шушы сыйфатын югалтмасын, яңаданяңа үрләр яуласын, укучылары арта барсын иде дигән теләктә калам! Уңышлар!!!»

***Илфия Тимергалиева,***
*Алабуга институты студенты*

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.